**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай**
**муниципаль районы**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-20-31
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-20-31
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«05» декабрь 2019 ел** **№ 374**

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Сукаеш авыл җирлегенең
Генераль план проекты буенча
ачык тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясына таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1. Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү.
2. Ачык тыңлаулар үткәрүнең инициаторы булып Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башлыгы тора.
3.Билгеләргә:
- уздыру вакыты: 2019 елның 10 декабреннән 2020 елның 13 гыйнварына кадәр 17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;
- үткәрү урыны: Азнакай районы, Олы Сукаеш авылы, Мәктәп урамы, 4-2 йорт.
- фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2020 елның 13 гыйнварына кадәр, Азнакай шәһәре, М. Солтангалиев урамы, 24 нче йорт, Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге; Олы Сукаеш авылы, Мәктәп урамы, 4-2 нче йорт, Сукаеш авыл җирлеге башкарма комитетына кертелә ала.
4. Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге башкарма комитетына:
- гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән

срокларда,Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча ачык тыңлауларны әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Кушымта нигезендә, Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегенең Генераль планы проекты турында фикер алышу буенча ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составын расларга.

6. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык М.З. Шәйдуллин

Азнакай муниципаль районы
Башлыгы карарына кушымта
« ___»_______ 2019 №__ ___

Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегенең Генераль планы проекты турында фикер алышу буенча ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләүче эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| *Эшче төркем рәисе:* | |
| Шәмсетдинов А.Х. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| *Эшче төркем секретаре:* | |
| Әюпова Р.Р. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече (килешү буенча) |
| *Эшче төркем әгъзалары:* | |
| Шәршфетдинова С.Ф. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Закирова З.З. | Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Сабирҗанов Н.Г. | Азнакай район Советының җирлекләр белән эшләү секторы мөдире |